**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 май № 308

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1043 нче карары белән расланган 2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумын раслау турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1043 нче карары белән расланган 2016 елга Татарстан Республикасының Инвестиция меморандумына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлекнең 6.1 нче пунктында:

«Химия җитештерүе» юнәлеше буенча текстка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Елына 37500 тонна куәтле альфа-олефиннар җитештерү» («Түбән Кама нефть химиясе» ГАЖ, Түбән Кама шәһәре);

«Электр җиһазлары, электрон һәм оптик җиһазлар җитештерү» юнәлеше буенча текстка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Түбән вольтлы электр саклагыч җиһазлар җитештерү буенча цех корпусы төзелеше» («КАЗАНЬЭЛЕКТРОЩИТ» җитештерү берләшмәсе» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Транспорт һәм элемтә» юнәлеше буенча текстка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу үзәге»ннән «Казан-Арена» стадионына кадәр аркан юлы («Гулливер» фәнни-проект берләшмәсе» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

«Югары Ослан авылыннан «Казан-1» тимер юл вокзалына кадәр аркан юлы» («Казанский ПеревозЪ» Төгәл Механика Үзәге ҖЧҖ, Югары Ослан муниципаль районы);

«Бүтән проектлар» юнәлеше буенча текстка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«8,6 мең кв.метр гомуми мәйданлы ЭКСПО-КАМА яңа күргәзмә үзәге төзелеше» («ЭКСПО-КАМА» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре);

«Теләче» сәнәгать паркы төзелеше» («Созидание» идарә итүче компаниясе» ҖЧҖ, Теләче муниципаль районы);

«Чүпрәле» муниципаль сәнәгать мәйданын үстерү» («Прогресс» муниципаль унитар предприятиесе, Чүпрәле муниципаль районы);

«Хэбэй провинциясенең эшмәкәрләр ассоциациясе (Кытай Халык Республикасы) һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы арасындагы хезмәттәшлек турында килешү кысаларында Чүпрәле муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла һәм тормышка ашырырга планлаштырыла торган инвестиция проектлары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\308.docx